БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 05 2026 ел № 187

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүлү полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Элемтә турында» Федераль законның 6 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә юл эшчәнлеге һәм автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 2 декабрендәге 341 карары белән расланган (2025 елның 26 мартындагы 119 номерлы үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүлү полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану Тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән аларны салу, күчерү, яңадан кору, автомобиль юлының бүлү полосалары чикләрендә аларны эксплуатацияләү элемтә линияләре һәм элемтә корылмаларын биләүче тарафыннан яисә алар хисабына, әлеге биләүчеләрнең автомобиль юлы биләүчеләре белән төзегән килешүе нигезендә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон нигезендә төзелешкә бирелгән рөхсәт нигезендә (әгәр дә мондый рөхсәт бирү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон нигезендә таләп ителсә) башкарыла. Әлеге килешү нигезендә инженерлык коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары биләүчеләре аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән аларны салу, күчерү, яңадан кору, эксплуатацияләү барышында мәҗбүри үтәргә тиешле техник таләпләр һәм шартлар каралырга тиеш (алга таба әлеге статьяда - мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов